| | |
|---|---|
| **ГЛАВА МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛКИ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**29.10.2020ел.** **Мәлки авылы** **№ 2**

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Мәлки авыл җирлегенең
Байморза авылында гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 11 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Байморза авылы, Горький ур., 20 нче йорт адресы буенча урнашкан Байморза авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Байморза авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2020 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Байморза авылы, Горький урамы, 20 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Байморза авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Байморза авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булмаган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

*а) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- материаллар алу белән су челтәрләрен ремонтлау;

*б) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

*в) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:*

- материаллар сатып алып зиратларны чистарту һәм ремонтлау,.»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Мәлки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мәлки авыл җирлеге башлыгы Ф.П.Поляков